СОВЕТ НИЖНЕСУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.К.Маркса, д.18а, с. Нижняя Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422158

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН СОН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
К.Маркс ур., 18а нче йорт, Түбән Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422158

тел.(факс): (85563) 3-01-41; e-mail: NSun.Mam@tatar.ru, www:mamadнsh.tatarstan.ru

Карар — Решение

№2-26 — 20 июнь, 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Түбән Сон авыл
җирлеге муниципаль милкенә карата
концессион килешү төзү турында
карар кабул итүгә ризалык бирү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Түбән Сон авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбән Сон авыл җирлеге башкарма комитетына коммуналь инфраструктура һәм башка коммуналь хуҗалык объектларына, шул исәптән су белән тәэмин итү объектларына, үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системаларына, мондый системаларның аерым объектларына хезмәт күрсәтүгә концессион килешү төзү турында карар кабул итүгә ризалык бирергә.

2. 1 нче кушымтада бирелгән күчемсез мөлкәтне концессион килешү объектлары итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар халыкка җиткерелгән (басылып чыккан) көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районыны Түбән Сон авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Гафиятуллинга йөкләргә.

Түбән Сон авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы — Ш.Гафиятуллин/

СОВЕТ НИЖНЕСУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

1 нче кушымта

Концессион килешү объектлары, шул исәптән техник-икътисадый күрсәткечләре, техник халәте, хезмәт срогы

| № п/п | объектның исеме | Кадастр номеры | урнашу урыны адресы ( торак пункт/ур.) | Техник параметрлар (мәйдан/диаметр/биеклек/озынлыгы һ.б.) | Гамәлгә керү елы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Түбән Сон авылы Суэтем башнясы | 16:26:170101:541 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Түбән Сон авылы | Водонапорная башня Н-12 м 3 с насосом ЭЦВ 5-6.3-80 металлическая | 1976 |
| 2 | Түбән Сон авылы су үткәргеч челтәре | 16:26:000000:4442 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Түбән Сон авылы | Сети водопровода протяженность 2970 м (материал -сталь) п/э D - 110 | 1976 |
| 3 | Колышчы авылы Суэтем башнясы | 16:26:510201:577 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Колышчы авылы | Водонапорная башня Н-12 м 3 с насосом ЭЦВ 5-6.3-80 металлическая. | 1975 |
| 4 | Колышчы авылы Су алу җайланмасы | 16:26:000000:4450 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Колышчы авылы | Сети водопровода протяженность 3220 (материал -сталь) п/э D - 110 | 1975 |
| 5 | Рәхмәт Аланы поселогы су үткәргеч челтәре | 16:26:170301:87 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Рәхмәт Аланы поселогы | Водонапорная башня Н-12 м 3 с насосом ЭЦВ 5-6.3-80 металлическая | 1980 |
| 6 | Рәхмәт Аланы поселогы Суэтем башнясы | 16:26:000000:4459 | РФ, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы, Рәхмәт Аланы поселогы | Сети водопровода протяженность 1108 м (материал -сталь) п/э D - 110 | 1980 |